**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Яңа Шашы авыл җирлеге Чембулат торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

“13” ноябрь 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Чембулат торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чембулат торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, тавыш бирү хокукына ия булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм алар янындагы территорияне төзекләндерү; ( Чембулат авылында обелиск әзерләү һәм урнаштыру (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү))

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Чембулат авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Яңа Шашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чембулат авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.